ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 май 2026 ел № 4553

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы Карары, Шәһәр Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2025 елның 3 декабрендәге 3/5 номерлы Карарының 18 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибен, 1 нче кушымтада каралганча;

2) даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү һәм бәяләү буенча комиссия составын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасында каралган чыгымнарны финанслауны 2025 елга Яр Чаллы шәһәре бюджетының «Транспорт» 04.08 бүлеге/бүлекчәсе буенча каралган акчалар хисабына 145 830 975,87 сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 14 маендагы
4553 номерлы карарына
1 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки)
шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне
гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында
Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Терминнар һәм билгеләмәләр Россия Федерациясе Бюджет кодексындагы мәгънәләрдә кулланыла.

3. Субсидия бирүнең максаты булып, 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару тора.

4. Субсидия, субсидия бирү турында килешү нигезендә, «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан бирелә.

5. Сайлап алуда катнашучылар категориясе – даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру буенча хезмәтләр күрсәтүче юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр.

Субсидия алучыларны – юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) эшчәнлек төре – Башкарма комитет белән төзелгән муниципаль контракт һәм (яки) даими йөртүләр маршруты картасы нигезендә, даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру;

2) 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле ай саен алынып бетмәгән керемнәр булу.

6. Субсидия алучыны билгеләү ысулы – тәкъдимнәр (алга таба – заявкалар) соратып алу.

7. Субсидия бирү ысулы – алынып бетмәгән керемнәрне кайтару.

8. Субсидияләр, шул исәптән Шәһәр Советының шәһәр бюджеты турында карарында (Шәһәр Советының шәһәр бюджеты турында Шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карарында) күздә тотылган субсидияләр турында мәгълүматлар, техник мөмкинлек булганда, субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләрен бюджет акчаларын төп бүлүчеләргә җиткергән көнннән соң килүче

көннән башлап 10 эш көне эчендә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба - тиешенчә - «Интернет» челтәре, бердәм портал) (бердәм портал бүлегендә) яисә «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (алга таба – шәһәр сайты) урнаштырыла.

9. Сайлап алу техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итү буенча дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) Башкарма комитет тарафыннан яисә даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (заявкаларын) карап тикшерү һәм бәяләү буенча комиссия (алга таба – комиссия) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Башкарма комитетның сайлап алуда катнашучылар белән үзара эшчәнлеге техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасында электрон формадагы документлардан файдаланып яисә әлеге Тәртип нигезендә кәгазь һәм электрон чыганактагы документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасыннан файдалануны тәэмин итү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

## 2 бүлек. Сайлап алуны үткәрү һәм субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

11. Әлеге карар бастырып чыгарылган көннән башлап өч эш көне эчендә, Башкарма комитет Җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланганнан соң һәм, техник мөмкинлек булганда субсидия турында мәгълүмат бердәм порталда бастырып чыгарылганнан соң яисә шәһәр сайтында урнаштырылганнан соң, сайлап алуны үткәрү турында белдерү әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе тарафыннан «Электрон бюджет» системасында урнаштырыла.

12. Контроль-күзәтчелек органнарының, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының актлары, юридик затларның һәм (яки) шәхси эшмәкәрләрнең мөрәҗәгатьләре кергән очракта, сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү срогы тәмамланырга өч эш көне кала Башкарма комитет сайлап алуны үткәрүгә үзгәрешләр кертә яки гамәлдән чыгара.

13. Белдерүгә үзгәрешләр кертү, субсидия алучыларны сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кабул итү тәмамлану датасыннан соңга калмыйча, түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

1) сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү срогы, мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килүче көннән башлап заявкаларны кабул итү тәмамлану датасына кадәр күрсәтелгән срок кимендә 3 календарь көн тәшкил итәрлек итеп озайтылырга тиеш;

2) субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр керткәндә субсидия алучыларны сайлап алу ысулын үзгәртү рөхсәт ителми;

3) заявкаларны кабул итә башлау датасы җиткәннән соң субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә, субсидия алучыларны сайлап алуда катнашучыларның заявкаларга үзгәрешләр кертү хокукын күздә тоткан нигезләмә кертелә;

4) субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, субсидия алучыларны сайлап алуда гариза биргән катнашучыларга субсидия алучыларны сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү турында хәбәр ителә.

Заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелү турында, сайлап алуны үткәрү турында белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып яисә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзаланган тиешле хат аша хәбәр ителә. Заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару турында, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасында яисә Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан имзаланган тиешле хат аша хәбәр ителә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару турындагы белдерү, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасында яисә шәһәр сайтында урнаштырылган көннән башлап, сайлап алу гамәлдән чыгарылган дип санала.

14. Сайлап алуда катнашучы, техник мөмкинлек булганда тиешле запросны «Электрон бюджет» системасында формалаштыру юлы белән яисә язма рәвештә, сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү турында Башкарма комитетка запрос җибәрергә хокуклы. Техник мөмкинлек булганда тиешле запросны «Электрон бюджет» системасында формалаштыру юлы белән яисә язма рәвештәге запрос, заявкалар соратып алуда катнашуга заявкаларны тапшыру срогы тәмамлану датасына кадәр ике көн алдан килгән очракта, мондый сайлап алуда катнашучыдан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү турында запрос кергән датадан соң килгән көннән башлап ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитет әлеге катнашучыга мондый нигезләмәләргә аңлатма җибәрә. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

15. Сайлап алуда катнашучылар 2026 елның 20 апреленә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы), Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) эш итү өчен файдаланылучы дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булып торган чит ил юридик заты (алга таба – офшор компанияләр), шулай ук, устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан арткан (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса) Россия юридик заты булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән), шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында турыдан-туры булмаган (күрсәтелгән ачык акционерлык

җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша тормышка ашырылган) катнашуы исәпкә алынмый;

2) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

3) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яки БМО Иминлек Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган, террорчылык оешмаларына һәм террорчыларга яки күпләп юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлекләрендә тормый;

4) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан акча алмый;

5) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) «Чит ил йогынтысы астында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

6) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият взнослары түләү буенча бурычы юк яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

7) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) хокукый акт нигезендә субсидия, башка субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү планлаштырылган шәһәр бюджетына кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук хокукый акт нигезендә бюджетыннан субсидия бирү планлаштырылган гавами-хокукый берәмлек каршында акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы юк (Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш);

8) юридик зат булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), ликвидацияләнү процессында тормый, аңа карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) эшчәнлеге туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

9) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) баш бухгалтеры (булган очракта) турында, субсидия алучылар (сайлап алуда катнашучылар) булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм физик зат турында мәгълүматлар юк;

10) шәһәр бюджетына салым булмаган түләүләр буенча бурычлар булмау.

16. Сайлап алуда катнашучыларның заявкалары, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон формада яисә Башкарма комитет тарафыннан Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча яки шәһәр сайтында, шулай ук kancel.chelny@tatar.ru электрон почта адресы буенча кабул ителә. Сайлап алу этаплары каралмаган. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кабул итү сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән датадан башлап биш календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

17. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон формада

заявка формалаштыра һәм тапшыра яисә шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча заявка;

1) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча тәкъдим (заявка);

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

4) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затны Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

5) 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне раслаучы документлар (шартнамәләр, белешмә-хисаплар, актлар, өземтәләр);

6) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычның булмавы яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавы турындагы мәгълүмат;

7) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

8) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүматны, сайлап алуда катнашучы турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик зат өчен).

18. Башкарма комитет ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында түбәндәге документларны соратып ала:

1) салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында мәгълүмат;

2) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан мәгълүматлар;

3) экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау турында мәгълүмат;

4) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яки БМО Иминлек Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган, террорчылык оешмаларына һәм террорчыларга яки күпләп юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлекләрендә тормау турында мәгълүмат;

5) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) «Чит ил йогынтысы астында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» Федераль закон нигезендә чит ил агенты булмау турында мәгълүмат.

19. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында аларны карау мөмкинлеге булган тиешле мәгълүмат дәүләт мәгълүмат системаларында булган очракта, Башкарма комитет, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең

15 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатында, сайлап алуда катнашучыдан документлар һәм мәгълүмат тапшыруны таләп итәргә хокуклы түгел (сайлап алуда катнашучы күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы буенча Башкарма комитетка тапшырырга әзер булган очрактан тыш).

20. Сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашу өчен заявкалар бирү срогы тәмамланганчы, сайлап алуда катнашу өчен заявкага үзгәрешләр кертергә хокуклы. Бу очракта мондый катнашучы тарафыннан элек җибәрелгән заявка кире алына.

Заявкалар соратып алуда катнашуга заявка биргән сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашу өчен заявкалар бирү срогы тәмамланганчы, мондый заявканы кире алырга хокуклы.

21. Сайлап алуда катнашучыларның заявкалары булган конвертларны ачу, заявкаларны соратып алу тәмамланган датадан соң икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла һәм беркетмәгә теркәлә.

22. Субсидия алучы булып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә, кергән заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкалары сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән критерийларга, категорияләргә, шартларга туры килә торган сайлап алуда катнашучылар санала. Кергән заявкаларны карау аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

23. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кире кайтару өчен нигезләр булып тора:

1) заявкада сайлап алуда катнашучының вәкаләтле затының имзасы булмау;

2) сайлап алуда катнашучы тарафыннан алдан бирелгән тәкъдимнәре заявкалары кире алынмаган килеш ике яки күбрәк заявка бирелү. Күрсәтелгән очракта әлеге катнашучыга мондый сайлап алуда катнашуга барлык тәкъдимнәре заявкалары кире кайтарыла.

24. Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә сайлап алуда катнашучының заявкасын кире кагу өчен нигезләр:

1) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

3) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявкаларның һәм (яки) документларның сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

4) билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатында сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

5) заявка сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелү.

25. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын бәяләү өчен Башкарма комитет түбәндәге критерийларны куллана:

1) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында каралган категориягә һәм сайлап алу критерийларына туры килүе - 50 процент;

2) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 15 пунктында каралган таләпләргә туры килүе – 50 процент.

26. Заявкаларны карап тикшерү түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

1) гаризаларны карап тикшерү өчен Башкарма комитетка керү мөмкинлеге ачылган көннән соң килүче 10 эш көне эчендә «Электрон бюджет» системасында. Техник мөмкинлек булганда, Башкарма комитетка «Электрон бюджет» системасына

керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән гаризалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмый ачыла;

2) әлеге тәртиптә билгеләнгән тәртиптә, сайлап алуда катнашучылардан заявкалар кабул итү тәмамланган көннән башлап 10 эш көненнән дә артмаган срокта комиссия тарафыннан.

27. Башкарма комитетка әлеге Тәртипнең 17, 18 пунктларында каралган документлар кергән көнне Башкарма комитет Җитәкчесе аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

28. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы әлеге Тәртипнең 17, 18 пунктларында каралган документларны туплый һәм аларны карап тикшерү өчен, сайлап алуда катнашучылардан заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән башлап бер эш көне эчендә, составы так, ләкин биш кешедән ким булмаган санда Башкарма комитет карары белән раслана торган комиссиягә җибәрә.

29. Комиссия эшчәнлегенең максаты булып тора:

1) сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 17, 18 пунктларында каралган заявкаларын сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кире кайтару өчен нигезләр булу яки булмау предметына карап тикшерү;

2) сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 17, 18 пунктларында каралган заявкаларын, заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә сайлап алуда катнашучының заявкасын кире кагу өчен нигезләр булу яки булмау предметына карап тикшерү;

3) сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү, субсидия алучыларның шәһәр бюджетыннан субсидия алу өчен сайлап алу үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) ачыклау;

4) субсидия күләмен киметү яки арттыру мәсьәләләрен карап тикшерү.

30. Комиссия эшчәнлегенең бурычы булып сайлап алуда катнашучыларның документларын карап тикшерү тора.

31. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

32. Комиссия әгъзалары хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссиядә карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;

4) карап тикшерүгә чыгарылган мәсьәлә буенча фикер белдерергә.

33. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиягә документлар кергән көннән башлап, өч эш көненнән дә соңга калмый, утырышны үткәрү датасын билгели;

2) комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

3) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

34. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук, комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын башкара.

35. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара;

2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;

4) әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралган форма буенча, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм аны, утырыш үткәрү көненнән соң килүче эш көненнән дә

соңга калмый, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.

36. Комиссия эшчәнлегенең формасы булып утырыш тора, ул сайлап алуда катнашучылардан заявкалар алу тәмамланган көннән башлап ике эш көне эчендә үткәрелә.

37. Составының кимендә өчтән ике өлеше катнашкан очракта, комиссия утырышы тулы хокуклы санала.

38. Комиссия әгъзалары утырышта шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карап тикшерелә торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы.

39. Комиссия сайлап алуда катнашучылардан кергән заявкаларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга, категорияләргә, шартларга туры килүен карап тикшерә.

40. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын һәм әлеге тәртипнең 17, 18 пунктларында каралган башка документларны карап тикшерү йомгаклары буенча комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, алар кабул ителгән дип санала. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала. Комиссия карары комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

41. Сайлап алуга йомгак ясау беркетмәсе, сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре нигезендә, бердәм порталда автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Башкарма комитет Җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, техник мөмкинлек булганда, имзаланган көннән соң килүче эш көненнән соңга калмый бердәм порталда һәм шәһәр сайтында урнаштырыла.

Сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, сайлап алу йомгакларын ясау беркетмәсенең беренче версияләре имзаланган көннән башлап 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, күрсәтелгән беркетмәләрнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

42. Әлеге Тәртиптә каралган нигезләр буенча тәкъдиме (заявкасы) кире кайтарылган яки кире кагылган сайлап алуда катнашучыга комиссия утырышы үткәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә белдерү кәгазе җибәрә.

43. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) субсидия алучы тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы булмаган күләмдә тапшырылу);

2) субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты ачыклану.

44. Субсидия бирү турындагы килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында формалаштырыла һәм техник мөмкинлек булганда яисә әлеге Тәртип нигезендә һәр як исеменнән эш итәргә хокукы булган затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

45. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы комиссия беркетмәсен алган көннән башлап өч эш көне эчендә, әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада каралган форма буенча субсидия бирү турында килешү проектын яисә субсидия бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе проектын (алга таба – карар проекты) әзерләүне һәм имзалау өчен, аларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне тәэмин итә.

46. Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгыннан карар проекты кергән көнне, Башкарма комитет Җитәкчесе аны имзалый һәм, теркәү һәм субсидия алучыга җибәрү өчен, Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.

Сайлап алуда җиңүче субсидия бирү турында Килешүне Башкарма комитеттан алган көннән башлап ике эш көне эчендә аны имзаламаган очракта, мондый сайлап алуда җиңүче субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

47. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат беркетмә имзаланган көннән башлап өч эш көне эчендә шәһәр сайтында урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

1) сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

2) заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

3) кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турында белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

4) субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

48. Субсидия алучы комиссия карарларына суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

49. Субсидия, субсидия бирү турында килешү имзаланган көннән соң килә торган 20 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, бюджет ассигнованиеләре һәм агымдагы финанс елына әлеге максатлар өчен шәһәр бюджетында каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, белешмә-хисап нигезендә ай саен бирелә.

Килешү, килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән типовой формалар нигезендә Башкарма комитет һәм субсидия алучы арасында, шулай ук башка оешма арасында төзелә.

Субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган элек бирелгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегән очракта, субсидия бирү турында килешү яклары арасында килешүнең яңа шартлары килештерелә яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаган очракта, килешүне өзәләр.

50. Субсидияне финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре бюджеты тора.

51. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = (Прj \times Зj) – Дj - Csb,$$

монда:

С - даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару;

Прj - j-нчы вакыт аралыгында транспорт чарасының маршрут буенча фактта йөрүе, км;

Зj - j-нчы вакыт аралыгында транспорт чарасының 1 км йөрүенә йөртүченең чыгымнар күләме, сум/км;

Дj - йөртүченең j-нчы вакыт аралыгында автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында халыкка пассажирлар йөртү буенча хезмәт күрсәтүгә бәйле алынган керемнәре, сум;

Csb - j-нчы вакыт аралыгында сайлап алуда катнашучы тарафыннан шәһәр бюджетыннан башка максатлар өчен алынган субсидияләр күләме.

52. Субсидия, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәгән булса, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучыга ачылган счетка күчерелә (Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә казначылык аша үткәрелергә тиешле субсидияләрдән тыш).

53. Субсидия бирү нәтиҗәсе - 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару.

54. Субсидияләр бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) булып, зурлыгы ≥0,8 булырга тиешле «даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә торган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтү ышанычлылыгы тора.

55. ($К_{расп}$) чоры өчен даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_{расп} = \frac{Q_{фактрейс}}{Q_{рейсрасп}} \text{ з } 0,8,$$

монда:

$Q_{фактрейс}$ - даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында йөртүләрне гамәлгә ашырганда башкарылган рейсларның факттагы саны;

$Q_{рейсрасп}$ - даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында йөртүләрне гамәлгә ашырганда расписаниедә билгеләнгән рейслар саны.

56. Субсидия алучы алынып бетмәгән керемнәрне җибәрә:

1) субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәтенә һәм дәүләтнеке булмаган фондларга мәҗбүри түләүләрне түләүгә;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бәйле рәвештә контрагентлар алдында барлыкка килгән кредитор бурычын түләүгә.

57. Субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чарасы булып, субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылу ачыкланган очракта, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак баш эш итүче һәм муниципаль финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук әлеге Тәртиптә билгеләнгән нәтиҗәләргә һәм күрсәткечләргә ирешмәгән очракта, шәһәр бюджетына субсидия акчаларын кире кайтару тора.

58. Субсидия алучы юридик затлар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда (кайтарганда) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алырга хокуклы түгел.

59. Субсидия алучылар, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм җирле хакимият тарафыннан күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булу яки, аларга ихтыяҗ булмаган очракта, күрсәтелгән акчаларны кире кайтару турында карар кабул иткәндә, мондый нигезләмәләрне хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда килешүгә кертү мөмкинлегенә ия (кирәк булганда).

60. Субсидия алучылар, субсидия алучылар белән төзелгән килешүләр нигезендә акча алучы затлар (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) аларга карата бюджет акчалары белән баш эш итүче тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешенә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә, дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарының тикшерүләрне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне субсидия бирү турында килешүгә кертү хакында ризалыгын белдерәләр.

Субсидия алучы тарафыннан акчалар киләчәктә башка затларга бирелгән очракта, субсидияләр бирү турындагы килешүдә әлеге Тәртипнең 53, 63-69 пунктларында күрсәтелгән нигезләмәләргә тиңдәш шартлар карала.

Субсидия алучы тарафыннан акчалар киләчәктә башка затларга бирелгән очракта, мондый затларга әлеге тәртиптә каралган нигезләмәләр кагыла.

61. Юридик зат булып торган субсидия алучыны берләштерү, кушу яки яңадан төзү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, килешүдә хокукый варис булып торган юридик затны күрсәтеп, йөкләмәдә затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән, килешүгә үзгәрешләр кертелә.

62. Юридик зат булып торган субсидия алучыны бүлү, бүлеп бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук юридик зат булып торган субсидия алучыны ликвидацияләгәндә яки шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучының эшчәнлеген туктатканда (Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктның икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы сыйфатында эшчәнлекне гамәлгә ашыручы шәхси эшмәкәрдән тыш), килешүне берьяклы тәртиптә өзү турында белдерү кәгазе һәм, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган һәм субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән йөкләмәләр турындагы мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү һәм кулланылмаган субсидия калдыгын Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару турында акт формалаштырып, килешү өзелә.

### 3 бүлек. Хисаплылыкка таләпләр һәм субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешенә контрольне (мониторингны) гамәлгә ашыру турында таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

63. Субсидия алучы, агымдагы елның 31 декабренә кадәр срокта, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы аша яисә Башкарма комитет адресына субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Башкарма комитет, субсидия алучыдан килгән көннән башлап 15 эш көне эчендә, хисапны тикшерүне гамәлгә ашыра, шул исәптән техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы аша.

64. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе субсидия алучы тарафыннан субсидия бирүнең тәртибе һәм шартлары үтәлүне тикшерә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә.

65. Башкарма комитетның финанс идарәсе гамәлгә ашыра:

1) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерүне;

2) субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә мониторингны.

66. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Башкарма комитет һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланганда, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта субсидия алучыга карата субсидия акчаларын шәһәр бюджетына кире кайтару рәвешендә җаваплылык чарасы күрелә.

Субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) әлеге Тәртипнең 54 пункты белән каралган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, Башкарма комитет өч эш көне эчендә субсидия алучыга кимчелек турында белдерү кәгазе һәм субсидия акчаларын шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрә.

67. Субсидия алучы, кимчелек турында белдерү кәгазен һәм субсидия акчаларын Яр Чаллы шәһәре бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә, субсидия акчаларын кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

68. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыгы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көнендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

69. Хисап финанс елы – субсидия алучы әлеге Тәртиптә каралган документларны Башкарма комитет адресына җибәргән ел.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алуны үткәрү турында белдерү

Башкарма комитетның 20___ елның «___» ___________ _____номерлы карары белән расланган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә Сезне, даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан ___________ мең сум күләмендә субсидия бирү өчен заявкалар соратып алуда катнашырга чакырабыз.

Субсидия бирүнең максаты булып, 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару тора.

Субсидия, субсидия бирү турында килешү нигезендә, «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан бирелә.

Сайлап алуда катнашучылар категориясе – даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтүче юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр.

Субсидия алучыларны – юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) эшчәнлек төре – Башкарма комитет белән төзелгән муниципаль контракт һәм (яки) даими йөртүләр маршруты картасы нигезендә, даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру;

2) 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле ай саен алынып бетмәгән керемнәр булу.

Субсидия алучыны билгеләү ысулы – тәкъдимнәр (заявкалар) соратып алу.

Субсидия бирү ысулы – алынып бетмәгән керемнәрне кайтару.

Субсидия турында мәгълүматлар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (алга таба – шәһәр сайты) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында урнаштырыла.

Сайлап алу техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итү буенча дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында ( алга таба – «Электрон бюджет» системасы) Башкарма комитет тарафыннан яисә даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү буенча комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетның сайлап алуда катнашучылар белән үзара эшчәнлеге техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасында электрон формадагы документлардан файдаланып яисә әлеге Тәртип нигезендә кәгазь һәм электрон чыганактагы документлардан файдаланып гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасыннан файдалануны тәэмин итү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучылар 2026 елның 20 апреленә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы), Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) эш итү өчен файдаланылучы дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булып торган чит ил юридик заты (алга таба – офшор компанияләр), шулай ук, устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан арткан (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса) Россия юридик заты булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән), шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында турыдан-туры булмаган (күрсәтелгән ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша тормышка ашырылган) катнашуы исәпкә алынмый;

2) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

3) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яки БМО Иминлек Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган, террорчылык оешмаларына һәм террорчыларга яки күпләп юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлекләрендә тормый;

4) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) Башкарма комитетның 20___ елның «___» ___________ _____номерлы карары белән расланган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 3 пунктында билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан акча алмый;

5) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) «Чит ил йогынтысы астында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

6) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм

иминият взнослары түләү буенча бурычы юк яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

7) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) хокукый акт нигезендә субсидия, башка субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү планлаштырылган шәһәр бюджетына кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук хокукый акт нигезендә бюджетыннан субсидия бирү планлаштырылган гавами-хокукый берәмлек каршында акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы юк (Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш);

8) юридик зат булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), ликвидацияләнү процессында тормый, аңа карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) эшчәнлеге туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

9) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) баш бухгалтеры (булган очракта) турында, субсидия алучылар (сайлап алуда катнашучылар) булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм физик зат турында мәгълүматлар юк;

10) сшәһәр бюджетына салым булмаган түләүләр буенча бурычлар булмау.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон формада заявка формалаштыра һәм тапшыра яисә шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча заявка;

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

4) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затны Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

5) 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне раслаучы документлар (шартнамәләр, белешмә-хисаплар, актлар, өземтәләр);

6) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычның булмавы яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмавы турындагы мәгълүмат;

7) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

8) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында мәгълүматны, сайлап алуда катнашучы турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны

бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик зат өчен).

Заявкалар соратып алуда катнашуга заявка биргән сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашу өчен заявкалар бирү срогы тәмамланганчы, мондый заявканы кире алырга хокуклы.

Сайлап алуда катнашучы, сайлап алуда катнашу өчен заявкалар бирү срогы тәмамланганчы, сайлап алуда катнашу өчен заявкага үзгәрешләр кертергә хокуклы. Бу очракта мондый катнашучы тарафыннан элек җибәрелгән заявка кире алына.

Сайлап алуда катнашучыларның заявкалары булган конвертларны ачу, заявкаларны соратып алу тәмамланган датадан соң икенче эш көнендә гамәлгә ашырыла һәм беркетмәгә теркәлә.

Субсидия алучы булып, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән бүлеп бирелә торган субсидия күләме чикләрендә, кергән заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча, заявкалары сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән критерийларга, категорияләргә, шартларга туры килә торган сайлап алуда катнашучылар санала. Кергән заявкаларны карау аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын кире кайтару өчен нигезләр булып тора:

1) заявкада сайлап алуда катнашучының вәкаләтле затының имзасы булмау;

2) сайлап алуда катнашучы тарафыннан алдан бирелгән заявкалары кире алынмаган килеш ике яки күбрәк заявка бирелү.

Заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү стадиясендә сайлап алуда катнашучының заявкасын кире кагу өчен нигезләр:

1) сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2) сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

3) сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявкаларның һәм (яки) документларның сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

4) билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатында сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

5) заявка сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелү.

Сайлап алуда катнашучы Башкарма комитетка, техник мөмкинлек булганда тиешле запросны «Электрон бюджет» системасында формалаштыру юлы белән яисә язма рәвештә сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү турында запрос җибәрергә хокуклы. Техник мөмкинлек булганда тиешле запросны «Электрон бюджет» системасында формалаштыру юлы белән яисә язма рәвештәге запрос заявкалар соратып алуда катнашуга заявкаларны тапшыру срогы тәмамлану датасына кадәр ике көн алдан килгән очракта, мондый сайлап алуда катнашучыдан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү турында запрос кергән датадан соң килгән көннән башлап ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитет әлеге катнашучыга мондый нигезләмәләргә аңлатма җибәрә. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма бирү аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.

Заявкаларны карап тикшерү түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

1) гаризаларны карап тикшерү өчен Башкарма комитетка керү мөмкинлеге ачылган көннән соң килүче 10 эш көне эчендә «Электрон бюджет» системасында. Техник мөмкинлек булганда, Башкарма комитетка «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән гаризалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килүче бер эш көненнән дә соңга калмый ачыла;

2) әлеге тәртип нигезендә, сайлап алуда катнашучылардан заявкалар кабул итү тәмамланган көннән башлап 10 эш көненнән дә артмаган срокта комиссия тарафыннан.

Сайлап алуда җиңүче субсидия бирү турында килешүне Башкарма комитеттан алган көннән башлап ике эш көне эчендә аны имзаламаган очракта, мондый сайлап алуда җиңүче субсидия бирү турында килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан тәкъдим ителгән заявка турында, сайлап алуда катнашучы турында тиешле сайлап алу белән бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга), шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (физик зат өчен) ризалык белдерә.

Сайлап алуда катнашучыларның заявкалары, техник мөмкинлек булганда тиешле запросны «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон формада яисә язма рәвештә 08:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт адресы буенча яки шәһәр сайтында, шулай ук электрон почта адресы kancel.chelny@tatar.ru буенча Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

Субсидия бирү турында килешү төзү срогы – ________________________.

Башкарма комитет
Җитәкчесе ____________________

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатында заявкалар соратып алуда катнашуга

ЗАЯВКА

1. Заявкалар соратып алуда катнашучы турында мәгълүмат:

Исеме: ____________________

Фирма исеме: ____________________

Урнашу урыны: ____________________

Фамилиясе, исеме, атасының исеме: ____________________

____________________

____________________

Почта адресы: ____________________

Электрон почта адресы: ____________________

Элемтә өчен телефон номеры: ____________________

Салым түләүченең идентификация номеры: ____________________

Сайлап алуда катнашучының гамәлгә куючыларының, коллегиаль башкарма орган әгъзаларының, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затның салым түләүче идентификация номеры: ____________________

2. Сайлап алуда катнашучы ________________________________
(оешманың исеме)

2026 елның 20 апреленә түбәндәге таләпләргә туры килә:

1) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы), Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган Россия Федерациясендә активлар белән арадаш (офшор) эш итү өчен файдаланылучы дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булып торган чит ил юридик заты (алга таба – офшор компанияләр), шулай ук, устав (җыелма) капиталында офшор компанияләрнең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше тулаем алганда 25 проценттан арткан (әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача

каралмаган булса) Россия юридик заты булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләгәндә, офшор компанияләренең Россия Федерациясендә оештырылган сатуларда акцияләре әйләнештә булган ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы (шул исәптән халыкара компания статусы белән), шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында турыдан-туры булмаган (күрсәтелгән ачык акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы аша тормышка ашырылган) катнашуы исәпкә алынмый;

2) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы турында мәгълүматлар булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

3) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) БМО Уставының VII бүлеге, БМО Иминлек Советы яки БМО Иминлек Советы карарлары белән махсус төзелгән органнар тарафыннан каралган вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында төзелә торган, террорчылык оешмаларына һәм террорчыларга яки күпләп юк итү коралын таратуга бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлекләрендә тормый;

4) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) Башкарма комитетның 20___ елның «___» ___________ _____номерлы карары белән расланган даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 3 пунктында билгеләнгән максатларга шәһәр бюджетыннан акча алмый;

5) субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) «Чит ил йогынтысы астында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

6) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият взнослары түләү буенча бурычы юк яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

7) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) хокукый акт нигезендә субсидия, башка субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү планлаштырылган шәһәр бюджетына кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук хокукый акт нигезендә бюджетыннан субсидия бирү планлаштырылган гавами-хокукый берәмлек каршында акчалата йөкләмәләр буенча срогы чыккан (җайга салынмаган) башка бурычы юк (Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш);

8) юридик зат булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) үзгәртеп оештыру (субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) булып торган юридик затка башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), ликвидацияләнү процессында тормый, аңа карата Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) эшчәнлеге туктатылмаган, ә шәхси эшмәкәр булып торган субсидия алучы (сайлап алуда катнашучы) шәхси эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеген туктатмаган;

9) дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булып торган субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) баш бухгалтеры (булган очракта) турында, субсидия алучылар (сайлап алуда катнашучылар) булып торучы шәхси эшмәкәр турында һәм физик зат турында мәгълүматлар юк;

10) шәһәр бюджетына салым булмаган түләүләр буенча бурычлар булмау.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда, техник мөмкинлек булганда «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон формада заявка формалаштыра һәм

тапшыра яисә шәхсән яки ышанычлы зат аша Башкарма комитетка түбәндәге документларны тапшыра:

1) әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча заявка;

2) гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ күчермәсе;

3) вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);

4) юридик затның оештыру документлары (устав; Россия Федерациясе законнары нигезендә оешкан юридик затны Россия Федерациясе территориясендә урнашу урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык; Бердәм дәүләт юридик затлар реестрына язма кертү турында таныклык), физик затны шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык;

5) 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 мартына кадәрге чорда даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне раслаучы документлар (шартнамәләр, белешмә-хисаплар, актлар, өземтәләр);

6) субсидия алучының (сайлап алуда катнашучының) бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият взнослары түләү буенча бурычы юк яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясының 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

7) бухгалтерлык балансы, финанс нәтиҗәләре турында хисап һәм аларга кушымталар;

8) сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында, сайлап алуда катнашучы турында сайлап алу белән бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга), шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (физик зат өчен) ризалык.

Сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турында, сайлап алуда катнашучы турында тиешле сайлап алу белән бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик затлар өчен) белдерә.

Вәкаләтле затның вазыйфасы ______________________________

Имза
М.У. (булганда)

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү буенча комиссия утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ №________

1. Сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны:

2. Катнашучы комиссия әгъзалары:

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|
| | |

Карар кабул итү өчен кворум бар.

3. Түбәндәге сайлап алуда катнашучылардан заявкалар керде:

1)________________________________________;

2)________________________________________.

4. Кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый заявкалар туры килми торган сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат:

| Сайлап алуда катнашучының исеме | Заявканы кире кагу нигезләре |
|---|---|
| | |
| | |

5. Субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме:

________________________________________

Комиссия әгъзаларының имзалары:

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
4 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында
килешү №______

Яр Чаллы шәһәре «__» __________ 2026

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, алга таба «Вәкаләтле орган» дип аталучы, бер яктан, ________________ исеменнән, _______________нигезендә эш итүче һәм икенче яктан ___________________, алга таба «Алучы» дип аталучы, ___________________ исеменнән, ________ нигезендә эш итүче, бергә «Яклар» дип аталучылар, даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү буенча комиссиянең ___________елның № _____ беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

1.1. Вәкаләтле орган, әлеге Килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан Алучыга субсидия бирә.

Субсидиянең гомуми күләме __________________________________ тәшкил итә.

Алучы тарафыннан субсидия җибәрелә:

1) субсидия алучы хезмәткәрләренең хезмәтенә һәм дәүләтнеке булмаган фондларга мәҗбүри түләүләрне түләүгә;

2) даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бәйле рәвештә контрагентлар алдында барлыкка килгән кредитор бурычын түләүгә.

1.2. Бирелә торган субсидия максатчан характерга ия һәм ул әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралмаган максатлар өчен файдаланыла алмый.

1.3. Субсидия 2026 елга шәһәр бюджетында каралган лимитлар чикләрендә бирелә.

1.4. Шәһәр бюджетыннан субсидия бирүне җайга сала торган хокукый актлар:

1) Шәһәр Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2025 елның 3 декабрендәге 3/5 номерлы Карарының 18 пункты;

2) Башкарма комитетның «Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә

ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында» 20___ елның «___» _______ ___ номерлы карары.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Вәкаләтле орган түбәндәге хокукларга ия:

2.1.1. әлеге Килешү буенча бирелә торган субсидияне Алучы тарафыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануга контрольне гамәлгә ашырырга;

2.1.2. әлеге Килешүне үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча Алучыдан өстәмә мәгълүмат сорарга һәм алырга.

2.2. Вәкаләтле орган түбәндәгеләргә бурычлы:

2.2.1. әлеге Килешүдә каралган күләмдә, тәртиптә һәм шартларда Алучыга субсидия күчерергә;

2.2.2. субсидия бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган очракта, субсидияне кире кайтару турында карар кабул итәргә.

2.3. Алучы, субсидия бирү шартларын үтәгәндә, шәһәр бюджеты акчалары хисабына субсидияне әлеге Килешү төзелгән көннән башлап ун эш көне эчендә алу хокукына ия.

2.4. Алучы түбәндәгеләргә бурычлы:

2.4.1. Башкарма комитетның _____ елның _______________ _____ номерлы карары белән расланган Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә каралган субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешергә;

2.4.2. Вәкаләтле органга әлеге Килешүгә кушымтада каралган форма буенча, нигезләүче документлары белән бергә, субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында еллык хисап тапшырырга;

2.4.3. әлеге Килешү буенча бирелә торган субсидиянең максатчан файдаланылуын тәэмин итәргә;

2.4.4. Субсидия алучы тарафыннан Башкарма комитетның 20___ елның _______________ _____номерлы карары белән расланган Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә һәм әлеге Килешүдә каралган тәртип, максатлар һәм шартлар бозылган очракта, субсидияне шәһәр бюджеты керемenә кире кайтарырга.

## 3. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары, хисаплылыкка таләпләр

3.1. Субсидия, ай саен түбәндәге срокларда, әлеге Килешүнең 8 бүлегендә күрсәтелгән счетка күчерелә: _______________________________________.

3.2. Алучының субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүе турындагы хисаплылыкка таләпләр булып хисаплылыкта күрсәтелгән мәгълүматларның тулылыгы, дөреслеге һәм тикшерә алырлык булуы тора.

3.3. Алучы 2026 елның 31 декабренә кадәр срокта, әлеге Килешүгә кушымтада каралган форма буенча субсидияне файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүе турындагы хисапны Вәкаләтле орган адресына тапшыра.

3.4. Әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирүнең мәҗбүри шартлары түбәндәгеләр:

1) Субсидия алучының, субсидия алучылар белән төзелгән Килешү нигезендә акча алучы затның (аларның устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр

катнашындагы дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләрдән, аларның устав (склад) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашындагы коммерцияле оешмалардан тыш) аларга карата бюджет акчалары белән баш эш итүче тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешенә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә, дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнарының тикшерүләрне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне субсидия бирү турында Килешүгә кертү хакында ризалыгы.

2) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлаштыру эшләнмәләре сатып алганда гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән һәм әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле башка операцияләрдән тыш, алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алуны тыю.

Субсидия алучы тарафыннан акчалар киләчәктә башка затларга бирелгән очракта, мондый затларга Башкарма комитетның 20___ елның _________________ _____номерлы карары белән расланган Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 53, 63-69 пунктларында күрсәтелгән нигезләмәләргә тиңдәш шартлар кагыла.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу срогы

4.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм Якларның үз йөкләмәләрен тулысынча үтәүләренә кадәр гамәлдә була.

4.2. Субсидия алучы тарафыннан субсидия максатчан файдаланылмау сәбәпле, кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасы шәһәр бюджетына күчерелгән көннән башлап өч эш көне эчендә әлеге Килешү Вәкаләтле орган тарафыннан срогыннан алда өзелергә мөмкин.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Алучы әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән субсидиядән максатчан файдаланмаган очракта, Алучы бюджет акчаларын максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралганча җаваплы.

5.2. Башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылу һәм (яки) нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәү ачыкланган очракта, өч эш көне эчендә Алучыга бозу очраклары турында белдерү кәгазе һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләп җибәрелә.

5.3. Алучы, бозу очраклары турында белдерү кәгазен һәм субсидияне шәһәр бюджетына кире кайтару турында таләпне алган көннән башлап 15 эш көне эчендә, субсидияне кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

## 6. Бәхәсләрне карап тикшерү тәртибе

6.1. Әлеге Килешү Якларның килешенүе буенча өзелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешү буенча барлык фикер каршылыклары һәм бәхәсләр Яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә.

6.3. Барлыкка килгән бәхәсне сөйләшүләр юлы белән җайга салу мөмкинлеге булмаган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә бәхәс Татарстан Республикасының Арбитраж Судында карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Башка шартлар

7.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язма рәвештә рәсмиләштерелгән, вәкаләтле затлар тарафыннан имзаланган һәм ике Якның да мөһерләре белән расланган булса, гамәлдә дип саналалар.

7.2. Әлеге Килешү, субсидия бирү турында Килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән Килешүне өзү турында өстәмә килешү (кирәк булганда) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән типовой формалар нигезендә Башкарма комитет һәм субсидия алучы арасында, шулай ук башка оешма арасында төзелә.

Субсидия бирү турында Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмауга китерә торган элек бирелгән бюджет йөкләмәләренең лимитлары кимегән очракта, субсидия бирү турында килешү яклары арасында Килешүнең яңа шартлары килештерелә яки яңа шартлар буенча Килешүгә ирешә алмаган очракта, Килешүне өзәләр.

7.3. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү өчен нигезләр булып субсидия бирүгә бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләренең лимитларын киметү тора.

7.4. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия дүрт нөсхәдә төзелде: ике нөсхә – Вәкаләтле органга, бер нөсхә – Алучыга, бер нөсхә – Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Территориаль бүлегенә.

7.5. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына торышы буенча, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калганы, хисап елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көне эчендә шәһәр бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 8. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында Яр Чаллы шәһәре бюджетыннан субсидия бирү турында ______елның «_____» ___________ № _____ Килешүгә кушымта

Субсидиядән файдаланунын нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап

| № т/б | Субсидия алучының исеме | Нәтиҗәлелек күрсәткеченең исеме | Килешү төзү датасына нәтиҗәлелек күрсәткечнең зурлыгы | Хисап датасына нәтиҗәлелекнең фактик күрсәткече | Субсидиядән файдалану юнәлеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Кушымта: раслаучы документларның күчермәләре.

Вәкаләтле затның вазыйфасы имза имзаның расшифровкасы

Башкаручы ____________________ ______________ _________________________

(имза) (вазыйфа) (имзаның расшифровкасы)

М.У. (булганда)

Башкарма комитетның
2026 елның 14 маендагы
4553 номерлы карарына
2 нче кушымта

Даими муниципаль маршрутлар буенча автомобиль һәм (яки) шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында сайлап алуда катнашучыларның заявкаларын карап тикшерү һәм бәяләү буенча
комиссия составы

| Вазыйфаи затның Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|
| Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе |
| Вилданов Руслан Флер улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| Мөхәммәтдинова Алиса Наил кызы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе транспорт һәм элемтә бүлегенең баш белгече |
| комиссия әгъзалары: | |
| Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| Максимова Регина Геннадьевна | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, икътисадый анализ һәм прогнозлау бүлеге башлыгы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ